**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ КАРАР _________

2022-2023 уку елында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

1.1. Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча 2022-2023 уку елында төп чаралар планы (1 нче кушымта);

1.2. Актаныш муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне контрольдә тоту комиссиясе составы (2 нче кушымта).

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә:

- армиягә алынуга кадәрге яшьләрне әлеге максатта хәрби хезмәткә әзерләүне тәэмин итә торган кирәкле чаралар күрергә:

- Актаныш районы хәрби комиссариаты тәкъдиме буенча хәрби хезмәт нигезләрен өйрәнү һәм оешмаларда эшләүче һәм хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек узмаган гражданнарны саклау өлкәсендә башлангыч белем алу өчен уку пункты булдыру;

- югары яисә урта хәрби белемле, шулай ук кирәкле белемнәре һәм югары мораль-эшлекле сыйфатлары булган югары һөнәри белем бирү учреждениеләренең хәрби кафедраларын тәмамлаучылар, запаста торучы офицерлар арасыннан белем бирү учреждениеләрен һәм уку пунктын укытучылар белән комплектларга;

- мәгариф учреждениеләренең һәм уку пунктының укыту-матди базасын камилләштерергә, хәрби хезмәт нигезләре буенча дәресләр үткәрү өчен мәгариф учреждениеләренең спорт залларыннан актив файдаланырга;

- «Тормыш иминлеге нигезләре» курсының «Хәрби хезмәт нигезләре» бүлеге буенча районның гомумбелем бирү учреждениеләренең предмет кабинетларын җиһазлау өчен методик әсбаплар, плакатлар һәм стендлар эшләүне һәм тиражлауны тәэмин итәргә.

3. Гражданнарны хәрби учет белгечлеге буенча әзерләүгә йөкләмә алып, Актаныш районы хәрби комиссариатына уку төркемнәрен тулы күләмдә туплауны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Актаныш технология техникумы директорына 2022-2023 уку елында Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләүне тәкъдим итәргә.

5. Оешма һәм предприятиеләр җитәкчеләренә, милек формаларына бәйсез рәвештә, даими эш урынын саклап калган килеш, хәрби исәпкә алу белгечлеге буенча әзерлеккә яисә укуга юнәлтелгән гражданнарны Россия Федерациясе хезмәте өчен түләүнең кимендә 10 минималь күләменнән, әмма предприятие яисә оешма хисабына хезмәткә түләүнең минималь күләменнән ким булмаган күләмдә даими эш хакы яисә уку урыны буенча стипендия түләп, эштән һәм укудан азат итүне тәкъдим итәргә. Имтиханнар тапшырганда Актаныш районы хәрби комиссариаты гаризасы буенча

производстводан аерылмыйча укучы чакырылучыларга, законда билгеләнгән тәртиптә уртача хезмәт хакын саклап, отпуск бирергә.

6. Муниципаль районның Финанс-бюджет палатасы рәисе К.Р.Каюмовага:

- хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек программасы бүлекләре буенча видеофильмнар һәм күрсәтмә әсбаплар (Калашников уку автоматлары , пневматик винтовкалар, һәр белем бирү мәктәбе өчен плакатлар комплектлары) алуга акча белән тэмин итүне карарга;

- Хәрби хезмәт курсы буенча гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү өчен җаваплы район вазыйфаи затлары белән укыту-методик җыемнар үткәрү өчен акча белән тэмин итүне карарга;

- гомуми белем бирү мәктәпләренең чыгарылыш сыйныф укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча биш көнлек уку җыеннары үткәрүгә акча белән тэмин итүне күздә тотарга;

- хәрби хезмәткә чакырылучыларга кыйммәтле бүләкләр бирү белән районыбызда “Аҗаган” район һәм зона хәрби-патриотик уенын оештыруга һәм уздыруга акча белән тәэмин итүне карарга.

7. Мәгариф идарәсенә, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә:

- яшьләрне хәрби-патриотик тәрбияләү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне көчәйтергә, хәрби-патриотик яшьләр, балалар берләшмәләре, клублар, секцияләр, түгәрәкләр, музейлар булдырырга;

- район мәгариф учреждениеләрендә “Аҗаган” хәрби-патриотик уенын үткәрергә;

- мәгариф учреждениеләрендә гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү уздыруны оештырырга;

- секцияләр, спортның хәрби-гамәли төрләре буенча түгәрәкләр үсешенә ярдәм итәргә.

8. Актаныш технологик техникумы директорына тәкъдим итәргә:

2022-2023 уку елында РФ хәрбиләре өчен хәрби учет белгечлеге буенча гражданнар әзерләү йөкләмәсен сыйфатлы үтәүне тәэмин итәргә;

- мобилизация ресурсларын хәрби исәптә туплау максатыннан дефицит хәрби учет белгечлеге буенча өстәмә әзерлек оештыру мөмкинлеген карарга.

9. Актаныш районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге дәүләт учреждениесенә законнарда билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарның хәрби учет белгечлеге буенча әзерлеген оештыруны тәкъдим итәргә.

10. «Актаныш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ профилактик медицина тикшерүләре һәм хәрби исәпкә кую нәтиҗәләре буенча 15-16 яшьлек егетләр белән дәвалау-сәламәтләндерү чараларын вакытында һәм тулы күләмдә үткәрүне тәкъдим итәргә.

11. Социаль һәм агарту бүлегенә, мәгариф бүлеге, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге белән берлектә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләргә патриотик тәрбия бирү, хәрби хезмәткә чакырылучыларның, хәрби хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының җәлеп итүчәнлеген күтәрү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары аша агитация-массакүләм чаралар үткәрүне тәэмин итәргә.

12. Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүнең торышын тикшереп тору комиссиясе РФ Хөкүмәтенең 2000 елның 05 июнендәге 436 номерлы карары белән расланган хәрби хезмәткә чакыруны оештыру һәм уздыру бәйгесен үткәрү турындагы нигезләмәгә, гражданнарны хәрби комиссариатларда, оешмаларда һәм учреждениеләрдә хәрби хезмәткә әзерләүнең һәм исәпкә алу-чакыру эшенең торышын тикшерү тәртибе турындагы РФ Кораллы Көчләре Генераль штабының методик күрсәтмәләренә таянырга.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
«___» _______ 2022 ел, № ___
1 нче кушымта

2022-2023 уку елында Актаныш муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планы

| № т/б | Чаралар | Башкаручы* | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| | 1. Оештыру чаралары | | |
| 1. | Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүгә йомгак ясау һәм яңа уку елына бурычларны билгеләү | хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы, мәгариф идарәсе | чакырылыш комиссиясе эше планы нигезендә |
| 2. | Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүнең торышы һәм яңа уку елына бурычларны билгеләү мәсьәләләре буенча кызыксынган барлык оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләренең укыту-методик киңәшмәсен уздыру | хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы, мәгариф идарәсе, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | 18.08.2022 елга кадәр |
| 3. | Төп планлаштыру документларын эшләү:<br>- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм әлеге әзерлек буенча төп чаралар планы турында карар проекты;<br>- хәрби комиссарның гражданнарны 2021-2022 уку елында хәрби хезмәткә әзерләү йомгаклары һәм 2022-2023 уку елына бурычлары турында боерыгы проекты;<br>- Районның хәрби комиссарының хәрби комиссариатына АТТ беркетү турындагы боерыгы проекты | хәрби комиссариат | 01.09.22 елга кадәр<br><br>25.08.22 елга кадәр |
| 4. | Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре турында муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе карарының күчермәләрен ТР хәрби комиссариатының чакырылыш бүлегенә төп чаралар планы белән тәкъдим итү | Хәрби комиссар ярдәмчесе (хәрби исәпкә алу буенча) | карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә |
| 5. | Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү мәсьәләләре буенча эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм методик тәкъдимнәр эшләү | хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы, мәгариф идарәсе | 2022 елның сентябре - 2023 елның мае |
| | 2. Оборона өлкәсендә башлангыч белемнәр алу | | |
| 1. | Районның гомуми белем бирү учреждениеләрен «Тормыш | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | даими |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | иминлеге нигезләре» курсы укытучылары белән комплектлаштыруны тикшереп тору | | |
| 2. | «ТИН» курсын укыту өчен белем бирү учреждениеләренә укыту һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү | Хәрби комиссариат, гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнар оборонасы, мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында |
| 3. | «ТИН» курсы укытучылары белән укыту-методик җыеннар үткәрүне оештыру | Хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | август, ел саен |
| 4. | Гражданнарның башлангыч белем алуын һәм белем бирү учреждениеләрендә гражданнар оборонасы буенча күнекмәләр алуын тикшереп тору | хәрби комиссариат, гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнар оборонасы, мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында |
| 3. Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләү | | | |
| 1. | хәрби хезмәт нигезләре укытучылары белән укыту-методик эш алып бару буенча районның хәрби комиссариатында штаттан тыш методик совет утырышы | Хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | 25.08.22 елга кадәр |
| 2. | Районның уку учреждениеләрендә хәрби хезмәт нигезләре курсы укытучылары вазыйфаларын комплектлаштыру | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | даими |
| 3. | «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы укытучылары белән өч көнлек укыту-методик җыемнар үткәрү. | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | 25.08.22 елга кадәр |
| 4. | хәрби хезмәт нигезләре курсы буенча гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү өчен җаваплы район вазыйфаи затлары белән укыту-методик җыемнар үткәрү | хәрби комиссариат | 27.09.22 елга кадәр |
| 5. | Мәгариф учреждениеләренең өлкән сыйныф укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча биш көнлек уку-кыр җыеннары үткәрү | Хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, Актаныш технология техникумы | 2023 елның мае |
| 6. | Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләү программасы бүлекләре буенча видеофильмнар һәм күрсәтмә әсбаплар алу | Хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, финанс-бюджет палатасы | 01.09.22 елга кадәр |
| 7. | Мәгариф учреждениеләрендә конкурслар үткәрү:<br>- хәрби хезмәт нигезләрен өйрәнү нәтиҗәләре буенча иң яхшы сыйныфка;<br>- хәрби хезмәт нигезләрен өйрәнү өчен иң яхшы укыту-матди база өчен;<br>- патриотик юнәлештәге күрсәтмә агитация карау. | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | 30.04.23 елга кадәр |
| 4. Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү. | | | |
| 1. | Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү мәсьәләләре буенча конференция үткәрү | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, | май-сентябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | |
| 2. | Мәгариф учреждениеләрендә батырлык дәресләре, Ватан тарихына багышланган класстан тыш чаралар үткәрү | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, Актаныш технология техникумы | уку елы дәвамында |
| 3. | Ватанны саклаучылар көненә һәм Җиңү көненә багышланган оборона-массакүләм һәм спорт эше айлыгы үткәрү | Хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | февраль-май 2023 ел |
| 4. | Районда хәрби хезмәткә чакырылучылар көне үткәрү | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | 23.11.22 елга кадәр 30.04.23 елга кадәр |
| 5. | «Аҗаган» хәрби-патриотик уенын, чакырылыш яшьләре катнашында спорт ярышларын оештыру һәм уздыру | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | февраль-май 2023 ел |
| 6. | ДОСААФ һәм АТТ уку оешмалары белән хәрби-шефлык эшен оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтү | Актаныш технология техникумы, мәгариф учреждениеләре | хәрби-шеф эше планы буенча |
| 7. | Хәрби-гамәли спорт төрләре буенча зона ярышларында катнашу | Хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | февраль-май 2023 ел |
| 5. Хәрби-исәпкә алу белгечлекләре буенча гражданнарны әзерләү | | | |
| 1. | Законда билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган эшләмәүчеләр арасыннан РФ хәрби комиссариат өчен гражданнарны хәрби учет белгечлеге буенча әзерләүне оештыру | Мәшгульлек үзәге, Актаныш технология техникумы, хәрби комиссариат | уку елы дәвамында |
| 2. | Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны хәрби учет белгечлеге буенча әзерләнүгә җибәрү өчен сайлап алу | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы | 01.10.22 елга кадәр 01.03.23 елга кадәр |
| 3. | хәрби учет белгечлеге буенча гражданнар әзерләү өчен ДОСААФ һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укыту төркемнәрен туплау | Хәрби комиссариат, Актаныш технология техникумы | 01.10.22 елга кадәр 01.03.23 елга кадәр |
| 6. Медицина тикшерүе | | | |
| 1. | Хәрби хезмәткә чакырганда гражданнарны медицина тикшерүен оештыру һәм уздыру | ХТК, РҮХ | апрель-июнь октябрь-декабрь |
| 2. | Хәрби исәпкә алуга башлангыч куелыш арасындагы чорда булган авырулар буенча гражданнарны тулысынча медицина тикшерүен тәэмин итү һәм хәрби хезмәткә чакырганда өстәмә медицина тикшерүе очракларын төшереп калдыру максатларында хәрби хезмәткә чакырылу | хәрби комиссариат, РҮХ, ХТК | ел саен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Тикшерүгә юнәлдерелгән гражданнар артыннан контрольне гамәлгә ашыру | ХТК, РҮХ | апрель-июнь, октябрь-декабрь |
| 7. Дәвалау-савыктыру эше | | | |
| 1. | Хәрби исәпкә алуга башлангыч куелыш вакытында гражданнарны медицина тикшерүе һәм медицина тикшерүе үткәрү һәм алар белән дәвалау-савыктыру чаралары уздыру | Район үзәк хастаханәсе | гыйнвар-март 2023 ел |
| 2. | Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга профилактик медицина тикшерүе үткәрү һәм дәвалау | Район үзәк хастаханәсе | 2022 елның сентябре, 2023 елның апреленә |
| 3. | Гражданнарның хәрби исәпкә алуга башлангыч куелышка кадәр физик үсешен, шулай ук хәрби хезмәткә чакырганда аларны хәрби хезмәткә вакытлыча яраксыз дип таныган очракта, диспансер күзәтү үткәрү | Район үзәк хастаханәсе | ел дәвамында |
| 4. | Гражданнарның ДОСААФ һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләренә хәрби учет белгечлеге буенча әзерлек эшләренә юнәлтелгән медицина комиссияләрен үткәрү | Район үзәк хастаханәсе | 2022 елның сентябреннән 2023 елның февраль аена |
| 5. | Хәрби хезмәткә чакыруны булдырмау максатларында хәрби комиссияләр эшендә наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән явызларча файдаланучы хәрби хезмәткә чакырылучыларны ачыклау буенча заманча ысуллар эшләргә һәм гамәлгә кертергә | Үзәк район хастаханәсе, хәрби комиссариат, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | ел дәвамында |
| 8. Гражданнарны хәрби хезмәткә ирекле әзерләү. | | | |
| 1. | Клублар, секцияләр, спортның хәрби-гамәли төрләре буенча түгәрәкләр эшен оештыру һәм аларның слетларын үткәрү | Хәрби комиссариат, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | уку елы дәвамында |
| 2. | РФ ОМ хәрби мәгариф учреждениесе составына керү өчен кандидатларны сайлап алуны оештыру һәм җибәрү | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | март-май |
| 3. | ВУЗ тәмамлаучылар арасыннан хәрби хезмәт нигезләре курсы укытучыларын үз вазифасына запас офицерларын сайлап алуны оештыру | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | май-июнь 2023 ел |
| 9. Гражданнарның хәрби-гамәли спорт төрләре белән шөгыльләнүләре | | | |
| 1. | Мәгариф учреждениеләренә спорт клубларын һәм секцияләрен ачуда ярдәм күрсәтү | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында |
| 2. | Районда хәрби-гамәли спорт төрләре буенча ярышлар үткәрү | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, | февраль-май, сентябрь-октябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | |
| 10. Контроль һәм ярдәм күрсәтү | | | |
| 1. | ДОСААФ уку оешмаларын туплау барышын контрольдә тоту | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе | сентябрь-февраль (ел саен) |
| 2. | ДОСААФ уку оешмаларында чыгарылыш имтиханнарын үткәрүне тикшереп тору | хәрби комиссариат, мәгариф идарәсе, ДОСААФ | график буенча |

**Искәрмә: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә буйсынмаган башкаручылар килештерү планына кертелә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына
______________ 2022 ел,
2 нче кушымта

Актаныш муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне контрольдә тоту комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов Л.С. | Актаныш районы хәрби комиссары. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Нуруллина Г.М. | Актаныш районы хәрби комиссариатының хәрби комиссарының (профессиональ психологик сайлап алу һәм гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны оештыру буенча) өлкән ярдәмчесе; |
| Шамсунова Л.Җ. | Актаныш технология техникумы директоры; |
| Шакирова Р.М. | Мәгариф идарәсе башлыгы; |
| Вәлиев Л.Ә. | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы. |

**Искәрмә: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган комиссия вәкилләре килештерү буенча комиссия составына кертелә.